Әмма алдакчыларга ышанмаска, алар белән элемтәне вакытында озә белергә кирәк.
Ельники районы прокуратурасы мошенниклар корбаны булган олкән яшьтәге жирле кешенен хокукларын яклаган. Кvзәтчелек ведомствосы гамәлләре нәтижәсендә пенсионерга анын банк счетыннан урланган 900 мен сумга якын акча кайтарылачак.
Алдау 2023 елнын ноябрендә килеп чыккан. Алтмыш оч яшьлек ир-ат vзен финанс учреждениесе хезмәткәре дип таныштырган билгесез кешедән шалтырату алган. Акчаларны янәсе мошенниклардан яклау сылтавы белән, шалтыратучы пенсионерны 712 мен сумны “куркынычсыз счетка” кvчерергә кvндергән. Ир-ат шул акчаларны кvрсәтелгән номерга кvчерә. Алданганын анлагач, полициягә морәжәгать итә.
Әлеге факт буенча «Мошенниклык» маддәсе дигән жинаять эше кузгатылган.
Тикшерv барышында урланган акчаларнын Санкт-Петербург кешесе хисабына керvен ачык-лый алганнар. Зыян кvрvченен мәнфәгатьләрен яклау максатыннан прокуратура Санкт-Петербургнын Калинин район судына нигезсез баю счеты хужасыннан акча чараларыннан файдаланган очен процентлар тvләтv турындагы дәгъва белән морәжәгать иткән.
Дәгъва таләпләренен гомуми суммасы якынча 900 мен сум тәшкил иткән. Суд прокуратуранын дәгъва таләпләрен тулысынча канәгатьләндергән.
Исегезгә тошерәбез: жинаятьчеләр челтәрләрдә баюларын дәвам итә. Уяу булыгыз, сентябрь аенда Мордовия халкы мошенникларга 28 млн сумнан артык акча биргән. Кvпме генә кисәтсәләр дә Саранск кешесе интернет аша мотоцикл алырга омтылып, 80 мен сумга якын югалткан. Россия Эчке эшләр министрлыгынын Саранск буенча 4 нче полиция бvлегенен дежур олешенә Мәскәv астындагы Красногорскнын 34 яшьлек кешесеннән гариза килгән. Ир-ат мошенникларнын корбаны булуын хәбәр иткән. Ачык-ланганча, морәжәгать итvче мессенджерларнын берсендә «Ява» мотоциклын тvбән бәядән сату турында кызыктыргыч тәкъдим кvргән. Жинаятьченен ышандыруларына ышанып, Мәскәv астында яшәvче мобиль кушымта аша кvрсәтелгән счетка 79 500 сум кvчергән. Сатучы мотоциклны оч кон эчендә китерергә вәгъдә иткән. Әмма килешенгән вакыт узгач, товар алынмаган, ә алдакчы элемтәгә чыгудан туктаган. Алдау корбаны булуын анлап, гражданин полициягә морәжәгать итә. Мошенниклык факты буенча жинаять эше кузгатылган. Шикләнелvченен шәхесен ачыклауга юнәлдерелгән оператив-эзләv чаралары vткәрелә.